МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ
И ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**15.02.2018_** **г. Казань** **№ __365-р______**

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак пунктлары җирләре (Казан шәһәре торак пункты җирләреннән тыш) составындагы җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2015 ел, 25 ноябрь, 2846-р карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы, “Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында” 1998 ел, 29 июль, 135-ФЗ Федераль законының 24.18 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе каршындагы кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләре турында бәхәсләрне карау буенча комиссиянең 2017 елның 8 декабрендәге № 285, 2017 елның 22 декабрендәге № 300 карарлары нигезендә:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак пунктлары җирләре (Казан шәһәре торак пункты җирләреннән тыш) составындагы җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2015 ел, 25 ноябрь, 2846-р карарына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 ел, 16 июль, № 1337-р карары белән

кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге эчтәлекле 4 пунктны өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«4. «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 ел, 29 июль, 135-ФЗ Федераль законының 24.18 статьясында каралган дәүләт кадастр бәяләве үткәргәндә кулланылган белешмәләрнең дөрес булмавы нигезле әлеге карарга кертелгән һәм тиешле салым буенча салым базасын билгеләгәндә салым түләүчеләрнең хәлен  яхшыртучы үзгәрешләр 2015 елның 1 гыйнварыннан соң булган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла».

2. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак пунктлары җирләре (Казан шәһәре торак пункты җирләреннән тыш) составындагы җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2015 ел, 25 ноябрь, 2846-р карары (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 ел, 16 июнь, № 1337-р карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак пунктлары җирләре (Казан шәһәре торак пункты җирләреннән тыш) составындагы җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен билгеләүнең 2015 елның 1 январена караган нәтиҗәләре дөрес булмавы сәбәпле, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Җир кишәрлекләренең кадастр бәясе» бүлегендә:

64691 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «64691 | 16:05:010102:77 | 2892,00 | 46,17 | 133523,64» |

597996 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «597996 | 16:34:040101:151 | 1718,43 | 72,25 | 124156,57» |

3. «Федераль дәүләт теркәвенә алу, кадастр һәм картография хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» Федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына күчемсез милек объектларынең кадастр бәясе үзгәрүе турындагы белешмәне билгеләнгән тәртиптә Күчемсез милек бердәм

дәүләт реестрына кертергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының www.mzio.tatarstan.ru адресындагы рәсми сайтына урнаштырырга.

5. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министр урынбасары Р.Р.Мерзакреевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**

В.В.Морозов
3-33